**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «20» декабреннән № 279

Яңа Чишмә муниципаль районы буенча 2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы

2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын раслау тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында»гы боерыгының 4.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә

муниципаль районының рәсми сайтында: http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «20» декабреннән
279 номерлы карарына
кушымта

2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы

| № т/б | Муниципаль берәмлек | Чик индексы (процентлар) |
|---|---|---|
| | | 01.01.2024 алып 31.12.2024 кадәр |
| 1 | Яңа Чишмә муниципаль районы | 2,5 |